

Россиядә 134 мен авыл бар. Белгечләр кон саен оч авыл юкка чыга, дип чан суга. Халык шәһәргә китv ягын карый. Сонгы сигез ел эчендә генә дә 8,5 мен авыл яшәvдән туктаган. Россия кvләмендәге саннар белән чагыштырганда, Мордовиядә хәлләр тотрыклы кvренсә дә, уйланырлык, борчылырлык проблемаларыбыз шактый.

Икенче яктан, беттек, юкка чыктык дип яшәсәк, бетәргә дә кvп калмый. Авыл кая бара, нинди тенденцияләр кvзәтелә, бу хакта гел язып торабыз. Минемчә, авыл vзенә кvрә бер дәvләт. Татар авылы гомер-гомергә vзенен эчке тормышы белән яшәгән. 16 гасырда ук татарлар авыл шартларында vзенен дәvләтчелеген сак-лап калган. Икътисад кына тvгел, гореф-гадәтләребез дә, рухыбыз да, гомумән, яшәешебез дә авыл аша формалашкан.       20 гасыр башында, янадан дәvләтчелек торгызылганда, авыллар ярдәмгә килvен онытмыйк. Анын vзгәрvенә замана сәбәпче. Ләкин ничек кенә булмасын, татар халкы очен авыл барыбер топ нигез булып кала бирә. Милләтебезнен рухын саклаучы да, vзанын билгеләvче дә ул. Онытмыйк, авылда яшәv шартлары кырыс. Анда эшләп яшәргә кирәк. Тормышны жигелеп тартып алып бармыйсын икән, авылда яшәп булмый. Элек юклык белән тормыш алып барсалар, хәзер барлык белән яшиләр.

Мәсәлән, Ельник районындагы кечкенә генә, сvнеп килгән Ликиньё (Шашка) авылында Кәмил Шекур улы белән Гелжихан Рәvф кызы Утешевлар әлегә авылны яшәтеп килvчеләрнен берсе. Бу жирдә аларнын кендек каны тамган, ата-бабалары хезмәт итеп яшәгән. Һәм алар да туган жирләренә тугърылыклы булып калалар; хезмәт итеп матур гына яшиләр. Кәмилнен әтисе – Шекур Мухай улы белән әнисе -  Рәбия апа - авылында хормәтле колхозчылар булып иген игкәннәр, бала-чага тәрбияләгәннәр, аларны олы тормыш юлына лаеклы кешеләр булып vстереп . Гелжиханнын да Рәvф әтисе кече Ватанынын хормәтле колхозчысы була, ә әнисе – Рафика апа, укытучы булып эшләгән. Кызына да, педагогик мирасны бvләк итеп, башлангыч сыйныф укытучысы булырга язган.

Кәмил Шекур улы Утешев, Акчеево топ мәктәбен тәмамлап, Краснослободск районы авыл хужалыгы техникумына механниклык профессиясен vзләштерергә дип укырга керә. Унышлы гына тәмамлап, районындагы «Сельхозтехника» олкәсенә профессиясе буенча хезмәткә урнаша. Гомере буе тырышып хезмәт итә.

Гелжихан Рәvф кызы Утешева Ликиньё, Вачеевка (Вачи) авыллары мәктәпләрендә башлангыч сыйныф укучыларын укырга-язарга ойрәтә, белем доньясына алып керә.

Укучылары шунын очен ана рәхмәтлеләр; хормәт итәләр укытучы апаларын. Киләчәккә омет итеп яши Утешевлар; ике малай тәрбияләп vстерәләр, балаларына белем бирәләр. Шәхси хужалыкларында мал-туар асрап, кош-корт, яшелчә vстерәләр. Тан әтәчләре белән торып, тон уртасында гына йокларга ятарга кvнеккән инде авыл кешеләре. Шулай тырышмасан, эш бармый ул. Шушы эшләрдән башка авыл тормышын кvз алдына да китерә алмыйбыз. Терлек асраудан әллә нинди зур файда килмәсә дә, авылда эш урынын булмаганда  очын-очка ялгап барырга, балаларны укытырга житеп бара. Бvген авылда vз-vзенне кайтгыртмасан, vзенә шогыль тапмасан, эш юк дип хокvмәтне сvгеп кенә яшәп булмый бит. Эштән курыкмаган кешегә авылда да менә дигән итеп яшәргә була һәм шулай бетеп барган авылларыбызны, шул исәптән Ликиньё авылын да яшәтvчеләр арасында Утешевларнын роле зур.

**Наилә Насырова**